РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2019 Олы Кайбыч ав. № 69

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле Кайбыч муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1 (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органын, башка дәүләт органын, җирле үзидарә органын, предприятиене, учреждениеләрне, башка оешмаларны үз исеме һәм элмә тактада урнаштырылырга тиешле башка мәгълүматны элмә тактада күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата), 2.4-2.7, 2.15 статьясының 2 өлеше, 3.6-3.7, 3.15 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген билгеләргә (Кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары исемлеге турында» 2019 елның 07 маендагы 31 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://kaybici.tatarstan.ru/.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башлыгы урынбасары Р.Р.Хәялиевка йөкләргә.

А.И.Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Башлыгының
2019 е. «20» декабрендә 69
номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле Кайбыч муниципаль районы Советы аппаратының вазыйфаи затлары исемлеге**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | 2.1 статья. Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу | -Советның оештыру бүлеге башлыгы |
| 2. | 2.4 статья. Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр | -Совет аппараты җитәкчесе;<br>-Советның оештыру бүлеге башлыгы |
| 3. | 2.5 статья. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яисә тагып йөрү | -Советның оештыру бүлеге башлыгы |
| 4. | 2.6 статья. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү | -Совет аппараты җитәкчесе;<br>-Советның оештыру бүлеге башлыгы |
| 5. | 2.7 статья. Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларыннан файдалану тәртибен бозу | -Совет аппараты җитәкчесе;<br>-Советның оештыру бүлеге башлыгы |
| 6. | 2.15 статьяның 2 өлеше. Террорчылыкны профилак-тикалау, аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару буенча коллегиаль орган карарын үтәмәү яисә бозу | - помощник Главы по вопросам противодействия коррупции. |
| 7. | 3.6 статья. Җирлекләр территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрне, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу | - коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе;<br>- Советның оештыру бүлеге Башлыгы;<br>-Советның оештыру бүлеге җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән эшләү буенча баш белгече. |
| 8. | 3.7 статья. Этләрне урамда йөрү тәртибен бозу | - коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе;<br>- Советның оештыру бүлеге Башлыгы;<br>-Советның оештыру бүлеге җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән эшләү буенча баш белгече. |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | 3.15 статья. Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү | - коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе;<br>- Советның оештыру бүлеге Башлыгы;<br>-Советның оештыру бүлеге җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән эшләү буенча баш белгече. |